КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 февраль г.Казань № 119

Тукай муниципаль районы, Яңа поселогы, Молодежная урамы, 26 нчы йорт адресы буенча күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрнең исемлеге һәм рөхсәт ителгән чик бәясе турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 6 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигый һәм техноген характердагы аварияләр, башка гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгән очракта, Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 5 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган мәсьәләләр буенча карар кабул итү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 12 октябрь, 787 нче карары белән расланган Табигый һәм техноген характердагы аварияләр, башка гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгән очракта, Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 5 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган мәсьәләләр буенча карар кабул итү тәртибе нигезендә, Тукай муниципаль районы, Яңа поселогы, Молодежная урамы, 26 нчы йорт адресы буенча күпфатирлы йортта гадәттән тыш хәл нәтиҗәләрен бетерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Тукай муниципаль районы, Яңа поселогы, Молодежная урамы, 26 нчы йорт (алга таба – күпфатирлы йорт) адресы буенча күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләр исемлеге: түбәне ремонтлау;

күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрнең рөхсәт ителгән чик бәясе 1 628,054 мең сум тәшкил итә.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин